**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Берьюлы өч һәм аннан да күбрәк бала туу белән бәйле рәвештә балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» Указына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Берьюлы өч һәм аннан да күбрәк бала туу белән бәйле рәвештә балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» 2008 елның 20 августындагы ПУ-397 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

берьюлы өч һәм аннан да күбрәк бала туган очракта гаиләгә 100 000 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата ярдәмне;

берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк яшь ярым тулмаган балалар тәрбияләүче гаиләләргә Татарстан Республикасында «Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әлеге айлык акчалата ярдәмне билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән датага билгеләнгән балалар өчен яшәү минимумы күләмендәге (алга таба – балалар өчен яшәү минимумы күләме) һәр балага айлык акчалата ярдәмне.

Берьюлы өч һәм аннан да күбрәк бала туган очракта бер тапкыр бирелә торган акчалата ярдәм һәм берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк яшь ярым тулмаган балалар тәрбияләүче гаиләләргә айлык акчалата ярдәм балалы гаиләләрнең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән социаль ярдәмнең башка чараларына хокукы булуына бәйсез рәвештә түләнә.

Берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк яшь ярым тулмаган балалар тәрбияләүче гаиләләргә түләнә торган айлык акчалата ярдәм күләме балалар өчен яшәү минимумы күләме үзгәргән айдан гариза бирмичә генә яңадан хисапланырга тиеш. Берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк яшь ярым тулмаган балалар тәрбияләүче гаиләләргә түләнә торган айлык акчалата ярдәм яңадан хисапланганнан соң шулай ук гариза бирмичә генә башкарыла.»;

б) 4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 08 сентябрь
№ 732